# Яшелчәләр













**Бармак уены «Яшелчәләр»**

**1 .Рәсемдә нәрсәләр ясалган? Исемнәрен ата.**

**2.Бармак уенын кабатла.**

**3. Шигырьнең эчтәлегенә туры китереп бармакларны бөкләп бар.**

**Үрнәк:** **Бу бармак- кыяр. Бу бармак -кәбестә. Бу бармак- кишер. Бу бармак –помидор. Бусы сарымсак булды.Менә кәрзинем тулды..**

# Уенчыклар













**Бармак уены «Уенчыклар»**

**Бабай алды барабан, Әни алды сикергеч,**
**Әби алды бөтерчек, Ә мин алам да зур туп,**
**Әти алды машина, Уйныйм тупны сикертеп.**

# Кошлар













Бу бармак –чыпчык,
Бусы-сыерчык,
Бусы-карлыгач,
Бусы –сандугач.

Ә бусы бик кечкенә,
Тимәгез нәниемә,
Нәнием –чәнтиемә.

# Кыргый хайваннар














Баш бармагым бүредер,
Имән бармагым-төлке,
Урта бармагым-бурсык,

Атсыз бармагым- аю,
Чәнти бармагым –куян,
Куянны кая куям?

# Җиләк-җимешләр













Баш бармак- балан,
Имән бармак-карлыган,
Урта бармак-бөрлегән,

Атсыз бармак –алма,
Чәнти бармагым-чия.
Кем күбрәк җимеш җыя?

# Өс киемнәре











- Баш бармак башлык кигән, Атсыз бармак чалбар кигән,
- Имән бармак итәк кигән, Чәнти бармагым киенмәгән.
- Урта бармак зур тун кигән, Әллә киенә белмәгән?
-

# Аяк киемнәре













Баш бармак башмак кигән,
Имән бармак итектән,
Урта бармак унты тапкан,

Атсыз бармак сандалидан,
Ә чәнтием читектән чиккән.
Читек киеп биеп киткән!

# Савыт-саба













**Баш бармак чынаяк ала,**
**Имән бармак - тәлинкә,**
**Урта бармак -чәнечке,**

**Атсыз бармак аш сала,**
**Чәнти бармагы ала кашык .**
**Утырырга,әйдә,ашык!**